**Контрольно - измерительные материалы**
**для проведения промежуточной аттестации**
**(тестирование)**
**по литературному чтению (татарскому)**
**(для изучающих татарский язык как родной)**
**1 класс**

**Назначение проверочной работы** - оценить уровень сформированности предметных результатов по итогам усвоения программы по учебному предмету «Литературное чтение (на татарском языке)» обучающимися 1 класса.

**Форма контроля:** чтение текста с письменным ответом на вопросы

**Структура КИМ**

Тест состоит из 1 части, которая включает текст, и ответы на вопросы по данному тексту

Время выполнения работы 30 минут.

Отметки за работу не выставляются

| Балл | 5 баллов | 3-4 баллов | 0 – 2 баллов |
|---|---|---|---|
| Уровень | повышенный | базовый | недостаточный |

**Перечень требований к уровню подготовки учащихся**

1. Понимать прочитанный текст.
2. Находить нужную для ответа информацию из прочитанного текста.

**Ответы 1 вариант**

1. Бүген Фәриданең туган көне.
2. Фәридә туган көнгә дусларын чакырды.
3. Фәридә бәхетле.
4. Әби шундый карт.
5. Өлкәннәрне хөрмәт итәргә кирәк

**Критерии оценивания**

| Части | Колличество баллов за задание | Количество баллов |
|---|---|---|
| Часть 1 | 1 балл за верный ответ | 5 |
| Максимальное количество баллов | | 5 |

**Текст для чтения**
**Вариант 1.**

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе, иртән иртүк торып, бик матур торт пешерде. Өстәлгә төрле-төрле тәмле ризыклар куйды.

Фәридәнең күлмәге дә бик матур. Аны әнисе тегеп бирде. Чәчләренә күлмәге төсле үк тасмадан күбәләкләр куйды.

Өйләре дә бик матур бүген аларның. Бөтен нәрсә ялт иткән. Барысы да чиста, пөхтә. Өстәлдә шундый матур чәчәкләр тора. Аларны әнисе алып кайткан. Фәридә нинди бәхетле! Тиздән дуслары да килеп җитәр. Фәридә әнисе янына аш бүлмәсенә керде.

- Әни, әни, дим, әйдә, әби бүген залга минем кунакларым янына чыкмасын, ә? Анда бүген шундый матур, ә әби шундый карт.

Әнисе башта берни аңламады. Аннары урындыкка барып утырды һәм сүзсез калды. Аның йөзе үзгәргән, кәефе юк иде.

1.Бүген кемнең туган көне?
2.Фәридә туган көнгә кемнәрне чакырды ?
3. Фәридә бәхетлеме?
4. Фәридә әбисе турында нәрсә диде?
5.Бу өзектән сез үзегез өчен нинди нәтиҗә ясадыгыз?

## I вариант

### 1 нче өлеше (А)

**А1**. Габдулла Тукай кем?

а) шагыйрь;
в) җырчы;
с) артист.

**А2**. Кайсы рәттә бары тик Г.Тукайның әсәрләре генә урнашкан?

а) “Бала белән күбәләк”, “Гали белән Кәҗә”, “Шүрәле “
в) “Су анасы,. “Каргалар оясы”, “Җиңү бәйрәме”
с) “Сарык белән кәҗә”, “Сыерчыклар, “Дәү әнием”.

**А3**. Ә.Бикчәнтәева “Үрдәк беренчелекне алган” әкиятендә үрдәк беренче урынга ничек чыга?

а) матур итеп җырлый;
в) шәп итеп биеп күрсәтә;
с) үз телендә матур итеп шигырь сөйли.

**А4**. Г.Лотфи “Сыерчыклар” шигырендә сыерчыкның чут-чут итеп сайравы –

а) үзенә пар эзләве;
в) аның оя сайлавы;
с) яз килүгә шатлануы.

**А5**. Р.Вәлиеваның “Ак песи”әкиятендәге соры песи ак песигә үсмәгәнсең Әле, ди. Ни өчен?

а) кечкенә буйлы;
в) гел уйнаган, әйткән сүзне тыңламый;
с) дуслыкның да, ачлыкның да нәрсә икәнен белми.

**А6**. Мәкальнең азагын тап "Дөньяда иң йомшак нәрсә – ... ”

а) мамык мендәр;
в) әнием кулы;
с) туган җир туфрагы.

**А7**. Халык авыз иҗаты әсәрләре булган рәтне тап.

а) санамыш, мәкаль, табышмак;
в) Г.Тукай “Ел фасыллары”, Г.Лотфи “Сыерчыклар”
с) Р.Вәлиева “Ак песи”әкияте, З.Хөснияр “Тукран тәүбәсе” әкияте.

**А8**. *“Җәен-соры, кышын –ак, Аңа шулай яхшырак”* , бу мисал нинди әсәр жанрына керә?

а) Санамыш;
в) такмак;
с) табышмак.

**А9.** “*Туган ил ул - алтын арышлар, Туган ил ул – зифа камышлар*” дигән шигырь юлларында билгеләнгән сүзләр –

а) рифмалашкан сүзләр;
в) сынландыру;
с) чагыштыру.

**А10**. З.Әхмәровның “Агачлар да авырый” хикәясендә агач нидән авырый?

а) салкыннан корый башлый;
в) кәҗә алмагач кайрысын кимерә;
с) балалар ботакларын сындыра.

**2 нче өлеше (В)**

Текстны укы.

**Яңа көрәк**

Әнвәрнең әнисе, ике зур кәрзин күтәреп, базардан кайтып керде. Шыплап тутырылган кәрзиннәрне күрүгә, Әнвәр әнисенең каршына йөгерде. Тәмле-тәмле нәрсәләр алып кайтканын белә иде инде ул аның.

- Яле, улым, әйтеп җибәр әле, бу кемгә? – диде аңа әнисе, кәрзиннәрнең берсенннән эре-эре, бик матур кызыл алмалар чыгарып.
- Миңа! – диде Әнвәр һәм әнисенең кулыннан ялт иттереп тартып та алды.
- Ә бусын кемгә бирик икән?

Әнисе кулына кечерәк кенә катыргы тартмага салынган аллы-гөлле торт күтәреп тора иде. Үзе һаман, елмаеп, Әнвәргә карый.

- Бусы да миңа! – диде Әнвәр, шатырдатып алмасын тешли-тешли.
- Ә бусы?!

Күр инде, әнисенең кулында – яңа пешкән җир җиләкләре! Менә бу яңалык, ичмаса! Пешеп тә өлгергәннәрме икәнни?

Әнвәр беравык, кулындагы алмасын тешләргә дә онытып, кызарышып, тулып пешкән җиләкләргә исе китеп карап торды.

- Я, бусы кемгә инде, ник дәшмисең? – диде әнисе.

- Ә бусымы? Бусы миңа да миңа инде аның! – диде Әнвәр, юеш иреннәрен җәеп елмая-елмая һәм, җиләкләр салынган кечкенә генә кәрзинне әләктереп китә дә башлады.

- Тукта әле, тукта! Бетмәде бит әле, - диде әнисе һәм, ничектер Әнвәргә серле генә карап, әлеге олы кәрзиннән өр-яңа, ялтырап торган бер көрәк чыгарды.

- Менә тутыкмый торган көрәк бу. Үзе җиңел генә, үзе үткен, тик саплап кына җибәрәсем бар. Бусы кемгә була инде? – дип сорады әнисе, нигәдер бу юлы бик җитди карап.

Әнвәр бер кулына – алма, икенчесенә җиләкләр тоткан килеш, әле көрәккә, әле кулындагы җимешләргә карап-карап торды да кинәт катгый бер карарга килеп:

- Ә-ә, һаман-һаман миңа гына ярамас. Алай дөрес түгел ул. Бусы инде әти белән сиңа булсын... – диде.

Әнисенең йөзеннән елмаю югалды. Шунда ук аяклары арыганлыгы исенә төште, ахры. Ул, күңелсезләнеп кенә урындыкка барып утырды да, авыр сулап, Әнвәрнең күзләренә текәлде

Нигә икән? (Р.Вәлиева)

B11. Әсәр ни өчен “Яңа көрәк” дип атала?

______________________________________________________________________

B12. Ни өчен Әнвәр көрәкне алмаган?

______________________________________________________________________

B13. Ни өчен әнисе күңелсезләнеп авыр сулаган?

______________________________________________________________________

B14. Кәрзиннән чыккан әйберләрне син ничек бүләр идең?

______________________________________________________________________

**Дөрес җаваплар:**

| № | җавап |
|---|---|
| А1 | а |
| А2 | а |
| А3 | с |
| А4 | в |
| А5 | с |
| А6 | в |
| А7 | а |
| А8 | в |
| А9 | а |
| А10 | в |